2. Әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада каралган рәвеш буенча төзелгән исем, бүләк алуга рөхсәт бирү турындагы үтенечнамә (алга таба – үтенечнамә) йә әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада каралган рәвеш буенча төзелгән исем, бүләк алудан баш тарту турындагы хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамә) исем, бүләк алган (исем, бүләк алудан баш тарткан) йә якын арада исем, бүләк

алачагы турында чит дәүләттән, халыкара оешмадан, сәяси партиядән, бүтән иҗтимагый берләшмәдән яисә башка оешмадан хәбәрнамә алган көннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла:

1) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторлары тарафыннан – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына (алга таба – Президиум);

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары рәисләре, профессиональ даими нигездә эшләүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан – Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенә (алга таба – Комиссия).

3. Кергән үтенечнамәләр, хәбәрнамәләр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге тарафыннан (алга таба – вәкаләтле бүлек) кабул ителә һәм теркәлә.

4. Үтенечнамә, хәбәрнамә әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтада каралган рәвеш буенча төзелгән чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең яисә башка оешманың мактаулы яисә махсус исемен, бүләген яисә бүтән мактау билгесен алуга рөхсәт бирү турындагы үтенечнамәләрне һәм аларны алудан баш тарту турындагы хәбәрнамәләрне теркәү журналына (алга таба – журнал) кергән көннәрендә үк теркәлә. Үтенечнамәнең, хәбәрнамәнең соңгы битләрендәге аскы уң почмакка аны теркәү турында тамга куела, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) кабул итү номеры һәм кергән дата (журналга кертелгән язма нигезендә);

2) үтенечнамәне, хәбәрнамәне теркәгән затның имзасы һәм тулы фамилиясе.

5. Журнал вәкаләтле бүлектә рәсмиләштерелә һәм алып барыла, рөхсәтсез алу тыелган урында саклана.

6. Журнал тегелгән, номерланган һәм таныкланган булырга тиеш. Төзәтелгән язмалар журналны алып бару һәм саклау өчен җаваплы зат тарафыннан таныклана.



7. Үтенечнамә, хәбәрнамә теркәлгәннән соң шул эш көнендә вәкаләтле бүлек тарафыннан Президиум, Комиссия каравына тапшырыла.

8. Президиум, Комиссия үтенечнамәне карау йомгаклары буенча карар кабул иткәнче, исем, бүләк алган дәүләт вазыйфасын биләүче зат үтенечнамә белән бергә исем бирүне раслый торган документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аның документларының төп нөсхәләрен әлеге Тәртипкә 4 нче кушымтада каралган рәвеш буенча ике нөсхәдә төзелгән кабул итү-тапшыру акты буенча вәкаләтле бүлеккә тапшыра.

9. Әгәр дәүләт вазыйфасын биләүче зат исемне, бүләкне хезмәт командировкасы вакытында алса яисә аларны алудан баш тартса, үтенечнамә, хәбәрнамә тапшыру срогы хезмәт командировкасыннан кайткан көннән исәпләнә башлый.

10. Әгәр дәүләт вазыйфасын биләүче зат аңа бәйле булмаган сәбәп аркасында үтенечнамәне, хәбәрнамәне күрсәтүне, исем бирүне раслый торган документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аның документларының төп нөсхәләрен тапшыруны әлеге Тәртиптә күрсәтелгән срокларда башкара алмаса, әлеге зат, мондый сәбәпне бетергәннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, үтенечнамәне, хәбәрнамәне күрсәтергә, исем бирүне раслый торган документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аның документларының төп нөсхәләрен тапшырырга тиеш.

11. Әлеге Тәртипнең гамәлдә булу көче кагыла торган Президиум әгъзалары, аларның үтенечнамәләрен канәгатьләндерү турында йә аларның үтенечнамәләрен канәгатьләндерүдән баш тарту турында Президиум тарафыннан карар кабул ителгәндә, тавыш бирүдә катнашмыйлар.

12. Әлеге Тәртипнең гамәлдә булу көче кагыла торган Комиссия әгъзалары, аларның үтенечнамәләрен канәгатьләндерү турында йә аларның үтенечнамәләрен канәгатьләндерүдән баш тарту турында Комиссия тарафыннан карар кабул ителгәндә, тавыш бирүдә катнашмыйлар.

13. Президиум, Комиссия тарафыннан үтенечнамә карау нәтиҗәләре турында мәгълүмат өч эш көне эчендә вәкаләтле бүлеккә җибәрелә, шулай ук үтенечнамә биргән дәүләт вазыйфасын биләүче затка хәбәр ителә.

14. Президиум, Комиссия дәүләт вазыйфасын биләүче затның үтенечнамәсен канәгатьләндерү турында карар кабул иткән очракта, вәкаләтле бүлек биш эш көне эчендә әлеге затка исем бирүне раслый торган документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аның документларының төп нөсхәләрен әлеге Тәртипкә 4 нче кушымтада каралган рәвеш буенча ике нөсхәдә төзелгән кабул итү-тапшыру акты буенча тапшыра.

15. Президиум, Комиссия дәүләт вазыйфасын биләүче затның үтенечнамәсен канәгатьләндерүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта, вәкаләтле бүлек 10 эш көне эчендә исем бирүне раслый торган документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аның документларының төп нөсхәләрен тиешле чит дәүләт органына, халыкара оешмага, сәяси партиягә, бүтән иҗтимагый берләшмәгә яисә башка оешмага җибәрә.

Тәртипкә
1 нче кушымта

________________________________
________________________________
________________________________
________________________________
________________________________
(Ф.И.А.и., биләгән вазыйфа)

Чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең яисә башка оешманың мактаулы яисә махсус исемен, бүләген яисә бүтән мактау билгесен (фән һәм спорт өлкәләреннән тыш) алуга рөхсәт бирү турында

ҮТЕНЕЧНАМӘ

Миңа ________________________________________
(нинди казанышлар өчен һәм кем тарафыннан бирелгән,
____________________________________________
нинди казанышлар өчен һәм кем тарафыннан бүләкләнгән)
____________________________________________
(мактаулы яисә махсус исемнең, бүләкнең яисә бүтән мактау билгесенең атамасы)
____________________________________________
(мактаулы яисә махсус исем бирүне раслый торган документларны, бүләкне
________________________________алырга рөхсәт бирегез.
яисә бүтән мактау билгесен бирү датасы һәм урыны)

Мактаулы яисә махсус исем бирүне раслый торган документлар, бүләк һәм аның документлары, мактау билгесе һәм аның документлары

____________________________________________
(мактаулы яисә махсус исем, бүләк яисә бүтән мактау билгесе атамасы)



____________________________________________
(мактаулы яисә махсус исем бирүне раслый торган документларның, бүләк яисә бүтән мактау билгесе документларының атамасы)

____________________________________________

20___ ел, «__» ________, № ____ кабул итү-тапшыру акты буенча

______________________________________тапшырылды.
(исеме)

«__» ____________, 20__ ел ________ ______________________
(имза) (имзаны аңлатып язу)

Тәртипкә
2 нче кушымта

________________________________
________________________________
________________________________
________________________________
________________________________
(Ф.И.А.и., биләгән вазыйфа)

Чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең яисә башка оешманың мактаулы яисә махсус исемен, бүләген яисә бүтән мактау билгесен (фән һәм спорт өлкәләреннән тыш)алудан баш тарту турында

ХӘБӘРНАМӘ

Сезгә ________________________________________
(нинди казанышлар өчен һәм кем тарафыннан бирелгән,
нинди казанышлар өчен һәм кем тарафыннан бүләкләнгән)
____________________________________________
(мактаулы яисә махсус исем,
бүләк яисә бүтән мактау билгесе атамасы)

алудан баш тарту турында карар кабул итүем турында хәбәр итәм.

«__» ___________, 20_ел ___________ ______________________
(имза) (имзаны аңлатып язу)

Тәртипкә
3 нче кушымта

____________________________________
____________________________________
____________________________________
____________________________________
____________________________________
(Ф.И.А.и., биләгән вазыйфа)

Чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең яисә башка оешманың мактаулы яисә махсус исемен, бүләген яисә бүтән мактау билгесен алуга рөхсәт бирү турындагы үтенечнамәләрне һәм аларны алудан баш тарту турындагы хәбәрнамәләрне теркәү
ЖУРНАЛЫ

| т/б № | Үтенечнамә йә хәбәрнамә | | | Үтенечнамә, хәбәрнамә биргән затның Ф.И.А.и., вазыйфасы | Карау нәтиҗәсе | Искәрмә | Үтенечнамә, хәбәрнамә кабул иткән җаваплы затның Ф.И.А.и., имзасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | керү датасы | номеры | кыскача эчтәлеге | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |



Тәртипкә
4 нче кушымта

____________________________________
____________________________________
____________________________________
____________________________________
____________________________________
(Ф.И.А.и., биләгән вазыйфа)

Кабул итү-тапшыру
АКТЫ

«__» ______________, 20__ ел ______________ шәһәре

__________________________________________________ тапшыра,
__________________________________________________ кабул итә

| т/б № | Чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең яисә башка оешманың мактаулы яисә махсус исеме, бүләге яисә бүтән мактау билгесе атамасы | Мактаулы яисә махсус исем бирүне раслый торган документларның, бүләк яисә мактау билгесе документларының атамасы |
|---|---|---|
| 1. | | |
| 2. | | |
| Барлыгы | | |

Тапшырды/кабул итте: Кабул итте/тапшырды:

__________________________ __________________________
(имза, имзаны аңлатып язу) (имза, имзаны аңлатып язу)

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 573. «Сугыш чоры балалары турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Сугыш чоры балалары турында» федераль закон проектын закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертергә.

2. «Сугыш чоры балалары турында» федераль закон проектын бәяләмә бирү өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенә җибәрергә.

3. «Сугыш чоры балалары турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Хөкүмәте бәяләмәсе белән Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

4. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына, шулай ук Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының Татарстан Республикасыннан сайланган депутатларына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасын хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.

5. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында күрсәтелгән федераль закон проектын караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми вәкилләре итеп Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Гыйльметдинов Илдар Ирек улын һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Захарова Светлана Михайловнаны билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 июне
№ 1334-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 574. «Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр турында» Федераль законның 51 һәм 53 статьяларына һәм «Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр турында» Федераль законның 51 һәм 53 статьяларына һәм «Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасын хуплауны үтенеп, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына, шулай ук Татарстан Республикасыннан сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына мөрәҗәгать итәргә.

3. Күрсәтелгән федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советыннан рәсми вәкил итеп Борһанов Рәфис Тимархан улын билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 июне
№ 1335-V ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**575. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2016 елның 21 апрелендәге 1204-V ДС номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2016 елның 21 апрелендәге 1204-V ДС номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле яңа 2 һәм 3 пунктлар өстәргә:

«2. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын бәяләмә бирү өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенә җибәрергә.

3. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Хөкүмәте бәяләмәсе белән Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.» ;

2) 2 – 4 пунктларны 4 – 6 пунктлар дип санарга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 июне
№ 1336-V ДС



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**576. «Хәрби хезмәт узган, эчке эшләр органнарында, Дәүләт янгынга каршы хезмәтендә, наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен тикшереп тору органнарында, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләрендә һәм органнарында хезмәт узган затларны һәм аларның гаиләләрен пенсия белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законының 64 статьясына үзгәреш кертү хакында» 1069216-6 номерлы федераль закон проекты турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Хәрби хезмәт узган, эчке эшләр органнарында, Дәүләт янгынга каршы хезмәтендә, наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен тикшереп тору органнарында, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләрендә һәм органнарында хезмәт узган затларны һәм аларның гаиләләрен пенсия белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законының 64 статьясына үзгәреш кертү хакында» 1069216-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 июне
№ 1337-V ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 577. «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 17 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Архангельск өлкә депутатлар Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында (инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә торак урыннар өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү, торак фондына каравына бәйсез рәвештә, мәсьәләсе буенча)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 17 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Архангельск өлкә депутатлар Собраниесенең закон чыгару инициативасын (инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә торак урыннар өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү, торак фондына каравына бәйсез рәвештә, мәсьәләсе буенча) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Архангельск өлкә депутатлар Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 июне
№ 1338-V ДС



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 578. «Куллану кредиты (заем) турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Архангельск өлкә депутатлар Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Куллану кредиты (заем) турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Архангельск өлкә депутатлар Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Архангельск өлкә депутатлар Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 июне
№ 1339-V ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 579. «Реклама турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ленинград өлкәсе Закон чыгару собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Реклама турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ленинград өлкәсе Закон чыгару собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Ленинград өлкәсе Закон чыгару собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 июне
№ 1340-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 580. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 2[1] һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Орел өлкә халык депутатлары Советының закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 2[1] һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Орел өлкә халык депутатлары Советының закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Орел өлкә халык депутатлары Советына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 июне
№ 1341-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 581. «Россия Федерациясе Салым кодексына үзгәрешләр кертү турында» 1078298-6 номерлы федераль закон проекты хакында (физик затлар керемнәренә салым максатларында салым агентлары буларак таныла торган оешмалар исемлеген арттыру өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе Салым кодексына үзгәрешләр кертү турында» 1078298-6 номерлы федераль закон проектын (физик затлар керемнәренә салым максатларында салым агентлары буларак таныла торган оешмалар исемлеген арттыру өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 июне
№ 1342-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 582. «Россия Федерациясе Җир кодексының 39[8] статьясына үзгәреш кертү турында» 1064542-6 номерлы федераль закон проекты хакында (төгәлләнмәгән төзелеш объектлары урнашкан җир кишәрлекләрен арендалау срогын үзгәртү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе Җир кодексының 39[8] статьясына үзгәреш кертү турында» 1064542-6 номерлы федераль закон проектын (төгәлләнмәгән төзелеш объектлары урнашкан җир кишәрлекләрен арендалау срогын үзгәртү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 июне
№ 1343-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 583. «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» 1075789-6 номерлы федераль закон проекты турында (мәдәни мирас объектларын мәгариф һәм фән учреждениеләренә түләүсез файдалануга бирү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» 1075789-6 номерлы федераль закон проектын (мәдәни мирас объектларын мәгариф һәм фән учреждениеләренә түләүсез файдалануга бирү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 июне
№ 1344-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 584. «Сәяси репрессияләр корбаннарын реабилитацияләү турында» Россия Федерациясе Законының $8^1$ статьясына үзгәреш кертү хакында» 1057404-6 номерлы федераль закон проекты турында (җинаять эшләре һәм административ эшләр материалларына тикшерүләр үткәрү мөмкин булмаган очракта гражданнарны сәяси репрессияләр корбаннары дип тану өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Сәяси репрессияләр корбаннарын реабилитацияләү турында» Россия Федерациясе Законының $8^1$ статьясына үзгәреш кертү хакында» 1057404-6 номерлы федераль закон проектын (җинаять эшләре һәм административ эшләр материалларына тикшерүләр үткәрү мөмкин булмаган очракта гражданнарны сәяси репрессияләр корбаннары дип тану өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 июне
№ 1345-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 585. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына кайбер федераль башкарма хакимият органнарының һәлак булган (вафат булган) хезмәткәрләре балаларына пособиеләр түләү мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» 1059772-6 номерлы федераль закон проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына кайбер федераль башкарма хакимият органнарының һәлак булган (ва-

фат булган) хезмәткәрләре балаларына пособиеләр түләү мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» 1059772-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 июне
№ 1346-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 586. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1060301-6 номерлы федераль закон проекты турында (иминләштерелгән зат дәүләткә карамаган бер пенсия фондыннан икенчесенә күчкәндә, дәүләткә карамаган пенсия фондларының үз йөкләмәләрен вакытында үтәмәгәне өчен җаваплылык билгеләү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1060301-6 номерлы федераль закон проектын (иминләштерелгән зат дәүләткә карамаган бер пенсия фондыннан икенчесенә күчкәндә, дәүләткә карамаган пенсия фондларының үз йөкләмәләрен вакытында үтәмәгәне өчен җаваплылык билгеләү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 июне
№ 1347-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 587. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 15.23[1] статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1063307-6 номерлы федераль закон проекты турында (норманы редакция ягыннан төгәлләштерү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 15.23[1] статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1063307-6 номерлы федераль закон проектын (норманы редакция ягыннан төгәлләштерү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 июне
№ 1348-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 588. «Янгыннан ихтыярый саклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 1073440-6 номерлы федераль закон проекты турында (физик һәм юридик затларның янгынны профилактикалауда һәм (яисә) сүндерүдә катнашу өчен берләшү хокукларын гамәлгә ашыруларына бәйле рәвештә иҗтимагый мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуны камилләштерү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Янгыннан ихтыярый саклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 1073440-6 номерлы федераль закон проектын (физик һәм юридик затларның янгынны профилактикалауда һәм (яисә) сүндерүдә катнашу өчен берләшү хокукларын гамәлгә ашыруларына бәйле рәвештә иҗтимагый мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуны камилләштерү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 июне
№ 1349-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 589. «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 1080143-6 номерлы федераль закон проекты турында («Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» Федераль законны куллану тәҗрибәсен исәпкә алып саклау объектларының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүне хокукый җайга салуны камилләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 1080143-6 номерлы федераль закон проектын («Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» Федераль законны куллану тәҗрибәсен исәпкә алып саклау объектларының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүне хокукый җайга салуны камилләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 июне
№ 1350-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 590. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына юл хәрәкәте һәм транспорт чарасын эксплуатацияләү кагыйдәләрен системалы рәвештә бозган өчен дифференциацияле җәза кертү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 1086493-6 номерлы федераль закон проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына юл хәрәкәте һәм транспорт чарасын эксплуатацияләү кагыйдәләрен системалы рәвештә бозган өчен дифференциацияле җәза кертү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 1086493-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 июне
№ 1351-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 591. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1093505-6 номерлы федераль закон проекты турында (лотереяләрне һәм азартлы уеннарны законсыз оештырган һәм үткәргән өчен административ җаваплылык чараларын көчәйтү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1093505-6 номерлы федераль закон проектын (лотереяләрне һәм азартлы уеннарны законсыз оештырган һәм үткәргән өчен административ җаваплылык чараларын көчәйтү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 июне
№ 1352-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 592. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.42 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Краснодар крае Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.42 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Краснодар крае Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Краснодар крае Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 июне
№ 1353-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 593. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 8.21, 8.22 һәм 8.23 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Красноярск крае Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 8.21, 8.22 һәм 8.23 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Красноярск крае Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Красноярск крае Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 28 июне
№ 1354-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 594. Татарстан Республикасында туристлык тармагын үстерү перспективалары турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы әгъзаларының һәм утырышка чакырылганнарның докладларын тыңлап фикер алышканнан соң Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы республика икътисадының керемле тармагы буларак туризмның халык хуҗалыгының 53 тармагына кумулятив, синергетик тәэсир итүен билгеләп үтә.

2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясе

нигезендә туризмны үстерү республика икътисадының динамик һәм тотрыклы үсешенә ярдәм итә, аның конкурентлыкка сәләтен арттыра һәм социаль-икътисадый үсешнең нисбәтле булуын тәэмин итә.

Туристлык тармагын үстерүнең төп юнәлешләре һәм чаралары «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында туризм өлкәсен һәм кунакчыллыкны үстерү» дәүләт программасында билгеләнгән, 2014 – 2015 елларда аны финанслау күләме 117,3 млн. сум тәшкил иткән.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы әгъзалары һәм утырышка чакырылганнар туристлык тармагы үсешенең төп күрсәткечләренең уңай динамикасын билгеләп үтә. 2015 елда республикага 2,7 миллионнан артык кеше килгән. Соңгы ике елда туристлар санының уртача үсеше 13,5 процент тәшкил иткән. Әлеге күрсәткеч буенча Татарстан Республикасы Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләреннән, Краснодар краеннан, Кырым Республикасыннан һәм Мәскәү өлкәсеннән соң алтынчы урында тора.

2015 елда туризм өлкәсендә күрсәтелгән хезмәтләр күләме, чиктәш тармакларны исәпкә алмаганда, 11,3 млрд. сум тәшкил иткән, бу 2014 елгы күрсәткечтән 12,8 процентка артык. Чиктәш тармакларны исәпкә алганда, туризм тармагының гомуми әйләнеше 2015 елда 18,4 млрд. сум тәшкил иткән.

Чиктәш тармакларның мультипликатив тәэсирен исәпкә алып, туризм өлкәсендәге хезмәт күрсәтүләрдән барлык дәрәҗәдәге бюджетларга кергән салым түләүләре 7,9 млрд. сум тәшкил иткән. Шул рәвешле, турист тарафыннан тотылган бер сум барлык дәрәҗәдәге бюджетларга 43 тиен китерә.

Тулаем региональ продуктында туризм өлеше бер процент тәшкил итә. Республиканың туристлык индустриясендә 40 меңнән артык кеше эшли. Туристлык операторларының бердәм федераль реестрында 93 туристлык операторы теркәлгән, аларның 90ы республика территориясендә эчке һәм читтән керү туризмы белән шөгыльләнә. 2015 елда эчке һәм читтән керү агымнарының үсеше 2014 ел белән чагыштырганда 10,6 процентка артыграк булган.

2015 елда республиканың туристлык инфраструктурасы яңа объектлар белән баетылды, урнаштыру коллектив чараларының гомуми саны 385кә җитте. Республика башкаласы кунакханәләренең уртача тәэмин ителеше 2015 елда 2014 ел белән чагыштырганда 6 процентка, ә бер кунакханә номерыннан уртача керем 9 процентка арткан.

Зеленодольск муниципаль районының «Свияжск» һәм Спас муниципаль районының «Бөек Болгар» туристлык-рекреация кластерлары «Россия Федерациясендә эчке һәм читтән керү



туризмын үстерү (2011 – 2018 еллар)» федераль максатчан программасына кертелде.

Республикага Кытайдан, Берләшкән Гарәп Әмирлекләреннән, Германиядән, Төркиядән, Венгриядән һәм Финляндиядән килүче туристлар санын арттыру эшенә аерым игътибар бирелә. Бу максатларда 27 реклама-мәгълүмат туры оештырылды; Давос коммуникацияләр форумы белән берлектә «Киләчәк юнәлешләре» III Казан халыкара туристлык форумы үткәрелде.

Биш чит телдә эшләүче 50 тәрҗемәче гид әзерләү эше тәмамланды. ФИНА-2015 дөнья чемпионатына әзерлек кысаларында 1300 белгеч өйрәтелде.

2020 елга Татарстан Республикасына килүче туристлар санын 3,8 млн. кешедән арттыру планлаштырыла.

Муниципаль берәмлекләр дәрәҗәсендә туризмны үстерү өчен шартлар тудыру дәүләт сәясәте өстенлекле юнәлешләренең берсе булып тора, аны гамәлгә ашыру муниципаль берәмлекләрнең социаль-икътисадый мәсьәләләренең кайберләрен хәл итәргә ярдәм итәчәк. Бу максатларда мәдәни һәм табигать мирасы объектларын торгызу, ял итү ресурсларын тәртипкә китерү, туризмның матди базасын яңарту һәм киңәйтү, инвестицияләр җәлеп итү кебек мәсьәләләрне хәл итәргә кирәк.

Татарстан Республикасында гамәлгә ашырыла торган круиз, вакыйгалы, изге урыннарга сәяхәт итү, мәдәни-танып белү, үзешчән, дәвалау-сәламәтләндерү туризмы һәм ялы, бизнес-туризм өлкәсендәге проектлар, шулай ук дөньякүләм һәм эчке туристлык ихтыяҗын һәм районнарның этник туризм, аучылык һәм балыкчылык туризмы, экологик, экстремаль туризм, авыл туризмы һәм социаль туризм өлкәсендәге туристлык потенциалының конкурентлы өстенлекләрен исәпкә ала торган планнар республиканың муниципаль берәмлекләрендә туризмны үстерү өчен зур мөмкинлекләр барлыгын күрсәтә.

Фикер алышу йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

I. Эчке һәм читтән керү туризмын үстерү буенча Татарстан Республикасында алып барыла торган эшне уңай дип танырга.

II. Тәкъдим итәргә:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

1.1. 2017 елга Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда эчке һәм читтән керү туризмы өлкәсендә яңа, шул исәптән инновацияле, проектларга субсидияләр бирүгә акчалар каральрга.

1.2. Шәһәр яны елга флотын яңартуның һәм аны тизйөрешле суднолар белән тәэмин итүнең мөмкин булган механизмнарын эшләргә, бу республикада су туризмын үстерүгә һәм «А.М. Горький исемендәге Зеленодольск заводы» ААҖ куәтләренең тәэмин ителешенә ярдәм итәчәк.

2. Туризм буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитетына эчке һәм читтән керү туризмын үстерү эшен активлаштырырга.

3. Туризм буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитетына Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән берлектә Татарстан Республикасына килүче туристлар агымының сезонлылыгын тигезләү максатларында республикада булган шифаханә-курорт базасында медицина туризмы үстерү мәсьәләсен карарга, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары белән берлектә сәнәгый һәм эшлекле туризмны үстерү эшен дәвам итәргә.

4. Туризм буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитетына Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән берлектә физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен туристлык объектларыннан файдалану мөмкинлекләрен арттыру чараларын күрергә.

5. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Туризм буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты белән берлектә балалар туризмы инфраструктурасы торышын, проблемаларны, шул исәптән закон чыгару характерындагы проблемаларны, һәм Татарстан Республикасында балалар туризмы үстерү перспективаларын өйрәнергә.

6. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына башкарма хакимиятнең кызыксынган органнары белән берлектә туризм өлкәсендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү, Татарстан Республикасының яңа проектларын һәм инициативаларын гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр әзерләргә.

7. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юллар хуҗалыгы министрлыгына туристлык зоналарында юллар челтәрен, транспорт һәм сервис инфраструктурасын камилләштерү һәм юл хәрәкәте иминлеген арттыру чараларын күрергә.

8. Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советына республиканың муниципаль берәмлекләрендә туризмны үстерү эшенең уңай тәҗрибәсен гомумиләштерүне һәм таратуны тәэмин итәргә.

9. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына:



9.1. Түбәндәгеләрнең мөмкинлеген карарга:

туристлык ихтыяҗын һәм районның туристлык потенциалының конкурентлы өстенлекләрен исәпкә ала торган туризмны үстерүнең муниципаль программаларын эшләү һәм кабул итү;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан шифаханә-курорт оешмалары өчен җир салымы ставкасы дәрәҗәсен киметү.

9.2. Туризмның перспектив юнәлешләре (этник, мәдәни-танып белү, экологик, балыкчылык, авыл, сәламәтләндерү, ял итү һәм рекреация) буенча яңа брендлар булдыру эшен активлаштырырга.

III. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына Татарстан Республикасында туризмны үстерүне мониторинглау эшен дәвам итәргә һәм 2017 елның I кварталында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты утырышында әлеге карарны үтәү барышын тыңларга.

IV. «Татмедиа» ААҖга массакүләм мәгълүмат чараларында туризмны үстерү проблемаларын, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең туризм өлкәсендәге эшенең уңай тәҗрибәсен яктыртырга, республиканы туризм өчен уңайлы регион буларак тышкы һәм эчке туристлык базарларында реклама-мәгълүмат ягыннан алга җибәрүгә ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

V. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Т.П. Ларионовага йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Арча шәһәре,
2016 елның 21 июне
№ 1292-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 595. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы утырышын 2016 елның 28 июнендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Арча шәһәре,
2016 елның 21 июне
№ 1293-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 596. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. «2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 251-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

2. «2016 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 252-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

3. «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 219-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

4. «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәреш кертү хакында» 230-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

5. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 215-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

6. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 8 һәм 32 статьяларына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 29 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 244-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

7. «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәреш кертү хакында» 239-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

8. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $55^2$ статьясына үзгәреш кертү һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында» 248-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

9. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 228-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

10. «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 243-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Физик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозучы коллекторлык эшчәнлегенә (бурычларны кире кайтару эшчәнлегенә) каршы көрәш буенча кичектергесез чаралар турында» 225-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

12. «Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 242-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәреш кертү хакында» 245-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 235-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 3 пунктының үз көчен югалтуын тану хакында» 240-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

16. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 250-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

17. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан сайлап куела яисә билгеләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен һәм бүтән мактау билгеләрен (фән һәм спорт өлкәләреннән тыш) алу тәртибе турында.

18. «Сугыш чоры балалары турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында.

19. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2016 елның 21 апрелендәге 1204-V ДС номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында.

20. «Хәрби хезмәт узган, эчке эшләр органнарында, Дәүләт янгынга каршы хезмәтендә, наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен тикшереп тору органнарында, җинаятьүтәтү системасы учреждениеләрендә һәм органнарында хезмәт узган затларны һәм аларның гаиләләрен пенсия белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законының 64 статьясына үзгәреш кертү хакында» 1069216-6 номерлы федераль закон проекты турында.

21. «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 17 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Архангельск өлкә депутатлар Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында (инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә торак урыннар өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү, торак фондына каравына бәйсез рәвештә, мәсьәләсе буенча).



22. «Куллану кредиты (заем) турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Архангельск өлкә депутатлар Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

23. «Реклама турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ленинград өлкәсе Закон чыгару собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

